Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгы
«18» 05 2015
№ 01-02/292

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм
элемтә министрлыгы
« 18 » 05 2015
№ П-70

Хокукый актларны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда рәсми бастырганда үзара хезмәттәшлек итү Регламенты турында

## БОЕРЫК

Хокукый актларны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырганда үзара хезмәттәшлекне оештыру максатыннан, **боерык бирәбез:**

1. Хокукый актларны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырганда үзара хезмәттәшлек итү Регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”на урнаштыру (бастыру) өчен хокукый актларның төп нөсхәләренең электрон үрнәкләрен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юллаганда Регламентка нигезләнергә киңәш итәргә.

3. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына урнаштырган (бастырган) чакта Регламентка нигезләнергә киңәш итәргә.

Татарстан Республикасы
юстиция министры
_______________ Л.Ю.Глухова

Премьер-министр урынбасары –
Татарстан Республикасы
мәгълүматлаштыру
һәм элемтә министры
____________Р.А.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгының
«18»_05_2015
№ 01-02/292
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм
элемтә министрлыгының
«18»_05__ 2015
№ П-70 боерыгы белән
расланган

Хокукый актларны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгарганда үзара хезмәттәшлек итү Регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент үзара мәгълүмати хезмәттәшлек итүчеләрнең Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Президенты актларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм дәүләт комитетлары һәм ведомстволарының Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве узган норматив хокукый актларын, шулай ук Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының хокукый актларын (алга таба - хокукый актлар) “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (http://pravo.tatarstan.ru) (алга таба - Портал) урнаштыру (бастыру) буенча Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртипләрен көйли.

1.2. Регламент “Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керүләре тәртибе турында” 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Републикасы законы һәм “Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе, Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы законнары проектларын тапшыру тәртибе турында” 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Указы, Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында” 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында” 2002 елның 18 июлендәге 426 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

1.3. Порталда урнаштырылган (бастырылган) хокукый актлар үзара мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан кире алына, гамәлдән чыгарыла яки алыштырыла алмыйлар.

## 2. Үзара мәгълүмати хезмәттәшлектә төп катнашучылар һәм объектлар

2.1. Үзара мәгълүмати хезмәттәшлектә төп катнашучылар булып торалар:
2.1.1. Хокукый актларның контроль нөсхәләре ияләре:
Татарстан Республикасы Президенты Аппараты;
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты;
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты;
башкарма хакимиятнең республика органнары;
Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары.
2.1.2. Норматив хокукый актларны Порталда урнаштыруны (бастыруны) гамәлгә ашыручы операторлар:
Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы;
Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары.
2.1.3. Порталның техник операторы:
“Татарстан Республикасының мәгълүмати технологияләр үзәге” дәүләт унитар предприятиесе (алга таба - “ТР МТҮ” ДУП).
2.2. Үзара мәгълүмати хезмәттәшлек объектлары булып торалар:
Татарстан Республикасы законнары;
Татарстан Республикасы Президенты актлары;
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актлары;
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары;
башкарма хакимиятнең республика органнарының норматив хокукый актлары (алга таба - башкарма хакимиятнең республика органнары актлары);

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары (алга таба - муниципаль хокукый актлар).

3. Мәгълүмат алмашу инфраструктурасы

3.1. Катнашучылар арасында үзара мәгълүмати хезмәттәшлек Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары законнарын һәм башка актларны Порталда (массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында 2014 елның 17 декабрендәге Эл № ФС77-60244 номерлы таныклык) урнаштыру (бастыру) эшендә транспорт чарасы сыйфатында файдаланылучы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша тәэмин ителә.

4. Үзара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәй ведомствоара системасы аша pdf форматында Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тарафыннан юлланган Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Президенты актларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан юлланган Дәүләт Советы актларын һәм аның Президиумы актларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан актның төп нөсхәсенең электрон образы рәвешендә pdf форматында portal.pravo@tatar.ru электрон адресына юллана торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының актларын (конфиденциаль булган яки дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булган актлардан һәм аларның аерым нигезләмәләреннән кала) Порталда урнаштыруны (бастыруны) гамәлгә ашыра.

4.2. Башкарма хакимиятнең республика органнары алар тарафыннан чыгарылган хокукый актларның контроль нөсхәләренең электрон образларын, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве узганнан соң, Порталда урнаштыру (бастыру) өчен pdf форматында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юллауны гамәлгә ашыралар.

4.3. Хокукый актларның контроль нөсхәләре ияләре тәэмин итәләр:

хокукый актларның контроль нөсхәләренең электрон образларын хокукый актларны Порталда урнаштыруны (бастыруны) гамәлгә ашыручы операторга үз вакытында юллауны;

хокукый актларның контроль нөсхәләренең электрон образларының аларны урнаштырганда (бастырганда) дөреслекләрен.

4.4. Хокукый актны Порталда урнаштырганда (бастырганда) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан башкарыла:

хокукый актның карточкасын формалаштыру (тутыру);

хокукый актның контроль нөсхәсенең электрон образын Интернет-кабинет аша кертү.

4.5. Муниципаль хокукый актны урнаштырганда (бастырганда) Татарстан Республикасында җирле үзидарә органы тарафыннан башкарыла:

муниципаль хокукый актның контроль нөсхәсенең электрон образын булдыру;

хокукый актның контроль нөсхәсенең электрон образының дөреслеген тәэмин итү;

хокукый актның карточкасын формалаштыру (тутыру);

хокукый актның контроль нөсхәсенең электрон образын pdf форматында Интернет-кабинет аша кертеп, хокукый актны Порталда унаштыру (бастыру).

4.6. "ТР МТҮ" ДУП тәэмин итә:

Порталның тоткарлыксыз эшләвен, шулай ук үзара мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан билгеләнгән ихтыяҗлар нигезендә аның үсешен һәм камилләшүен;

Порталга керүнең югары тизлектә һәм ышанычлы булуын;

Порталның мәгълүмати куркынычсызлыгын, шул исәптән Порталның мәгълүмат чыганакларын санкцияләнмәгән керүләрдән саклауны;

Порталдан кулланучылар интерфейсына керүгә техник мөмкинлекне;

хокукый актларны урнаштыру (бастыру) өчен җаваплы затларның, мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларны исәпкә алу язмаларын (булдыру, төзәтмәләр кертү, юкка чыгару) алып баруны.

## 5. Хокукый актларның контроль нөсхәләренең электрон образларын тапшыру һәм аларны Порталда урнаштыру (бастыру) вакытлары

5.1. Хокукый актны Порталда бастыру турында карар кабул ителгән очракта Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, түбәндәгеләр белән билгеләнгән вакыт бетәргә 4 көннән дә соңга калмыйча, хокукый актның контроль нөсхәсенең электрон образын Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшыралар:

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе, Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы законнары проектларын тапшыру тәртибе турында” 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм боерыкларын бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керүе тәртибе турында” 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы карары.

5.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының дәүләт теркәве узарга тиешле актлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Республика башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында” 2002 елның 18 июлендәге 426 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә урнаштырылалар (бастырылалар).

5.3. Норматив хокукый актларны Порталда урнаштыру (бастыру) эшен гамәлгә ашыручы оператор хокукый актны норматив хокукый актларны рәсми бастыруның закон белән каралган вакытлары чыгарга 1 көннән дә кимрәк вакыт калганчы урнаштыра.